Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге
Башкарма комитеты

КАРАРЫ

2019 елның 24 декабре № 12

Чистай муниципаль районының
Каргалы авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында (Михайловка авылы гражданнар җыенының 2019 елның «14» ноябрендәге 1 номерлы карары, Каргалы авылы гражданнар җыенының 2019 елның «15» ноябрендәге 1 номерлы карары) Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю буенча тәкъдим ителгән Тәртипне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары аша игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http:/chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

Каргалы авыл
җирлеге башлыгы М.А.Заһидуллин

Чистай муниципаль районы
Каргалы авыл җирлегенең
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 24 декабре 12 номерлы
карары белән расланды

Чистай муниципаль районының
Каргалы авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 10 мартына кадәр Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, балачактан инвалид, 1 төркем инвалидлардан тыш, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыенда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү кәгазе (хәбәрнамә) бланкы, Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерү юлы белән яисә имза куеп тапшыру, яки почта элемтәсе аша җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, тулы күләмдә яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, почта күчерүләре (исәп-хисап оешмаларын) Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша, яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча), акча күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып килү касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ТР Чистай муниципаль
районының
Каргалы авыл җирлеге
гражданнарының үзара салым
акчаларын җыю Тәртибенә
кушымта

ТР Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү турында

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

Түләүченең Ф. И. атасының исеме

________________________________________________________________________

Адрес: ____________________________________________________________

____________________________________________________________ нигезендә

Сезгә, түбәндәге реквизитлар буенча: ________________ срогына кадәр, __________ суммада, чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:_________________________________________________

Алучы Банк БИК _____________________________________

Сч. № _________________________________

Алучы Сч. № ________________________________________

ИНН _________________________________________

КПП _________________________________________

КБК _______________ ОКАТО __________________

Түләү билгеләү

________________________________________________________________________

Җитәкче _________________ _______________________________________

М.П. (имза) (тулы имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - - -

хәбәр (хәбәрнамә) № _____

________________ сум күләмендә

Түләүченең Ф. И. атасының исеме _________________________________________

Адрес: ________________________________________________________________________

Алды «__» _______________ 20__ ел. ____________________________________

(түләүче имзасы)

Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше Каргалы авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.